# КАЛУШ

Насыйр шатлыгыннан үзенең баскычтан төшкәнен сизми дә калды. Ул чалбар кесәсендә шылтыраган өч сум акчаның татлы тавыш берлә тиз генә өстенә пальтәсен, башына бүреген киеп, шул әллә ничә җиреннән тишелеп бетеп, аяк киемлегеннән битәр балык тотар өчен сөзгегә охшаган калушына аягын сузды. Аягы бик күп тәҗрибәләр берлә бу калушның ачы суык көннәрдә бик салкын, бу калушның эче сазлы көннәрдә бик былчырак идекен белгәнгә, ул калушка барасы килмәгән, ул калушка керәсе килмәгән кебек булып китте. Насыйр эченнән генә аягын җуатып: «Кер, кер, курыкма, актык керүең, әллә ышанмыйсыңмы?» Дәлиле ныгая төшсен өчен кесәсендәге көмеш тәңкәләрне шылтыратып җибәрде. Аяк, көмеш тавышларын ишетер-ишетмәс салкын, былчырак калушның эченә үзен тыкты. Аның керүе берлә калушның эченә җыелган сулар кысылышып, шыбыр-шыбыр иткән тавышлар чыгарып, сөйләшә башладылар. Насыйр үзенең шул начар ертык калушны җиңүенең ләззәтене озайта төшәр өчен, тагы аякларын кузгатып куйды. Калушлардагы былчырак су тагы төрле тавышлар чыгардылар. Насыйр, кесәсендәге акчаны капшап карап, һәммәсе дә сәламәтлегенә ышангач, ишектән ук кебек атылып чыкты. Ул, бер сикерүдә калуш кибетенә барып җитәсе килгән кеше кебек, ашыгып-ашыгып базарга таба юнәлде. Капкадан чыгуы берлә аның күз алдына уйсурак җиргә җыелган су күренде. Насыйрның юлы аннан булмаса да, ул, актык мәртәбә шул калушның хезмәтен күрер өчен, актык мәртәбә калушка, аның тишегеннән курыкмавын белдерер өчен, туп-туры суга таба юнәлде. Ул калушның бөтен тишегеннән аккан суга, баскан саен калушның эчендә ишетелгән тавышларга илтифат итмәенчә, акрын гына бик вәкарь берлә генә суның бер башыннан икенче башына кадәр йөреп чыкты. Корыга чыгып баскач та ул, бөтен тишегеннән су ага торган калушына карарга тотынды. Ул, үзенең дошманын җиңгән солдат кебек елмаеп, аның тишекләреннән аккан судан, аның эчендә шыл-тырый торган былчырактан көлә башлады. Калуштан үчне ныклап алыр өчен, аның шул былчырактан газапланганын яхшылабрак

күрер өчен, ул, әле бер аягын, әле бер аягын селкетеп суларны шыкырдата, аягы белән калушның төрле тишекләреннән җыелган суны куып чыгара башлады. Калушның тишекләре бик күп булса да, Насыйр, боларның барысы белән дә бик таныш булганга, боларның берсен дә күзеннән ычкындырмады. Ул боларның күбесенең буйларыны, тирәнлекләрене дә белгәнгә, кайсыларын ямамакчы булып та, әллә ничә энә сындырып, әллә никадәр ачуы килгәнгә, ул менә шуларның һәммәсеннән дә берәм-берәм бүген ачуын алмакчы булды. Шуның өчен ул калушның йөзендә озын ертыктан суның күбекләнеп чыгуыннан, калушның ямау урынындагы бөрмәле ертыктан насос кебек атылып чыгуыннан, калушның башындагы зур тишектән чишмәдән аккан кебек агуыннан, калушның табанындагы тишектән чыгыр-чыгыр итеп суның этелүеннән дә ләззәт ала иде. Ләкин аның бик күптән ачуын китерә торган, кыш буе аягын туңдырган, бөтен яз буе итеген, чолгавын, аягын былчыраткан калушның төбендәге тишекләреннән генә ачуы ничек алынганны күрмәве, андагы тишекләрнең ничек иттереп сазлы суны коюларын күреп шатлана алмавы моның үченең манзарәсене азрак киметә иде. Шуның өчен ул аягын тагы суга манчып алып, бик тиз күтәреп карарга да уйлады, ләкин шул арада бик чабып килә торган атны күрүе аны ул фикердән кайтарды. Ул үзенең кесәсендә өч тәңкә акчасы барлыгыны, үзенең бу кабахәт калушыннан аерылу көне килеп җиткәнне хис итеп, шул шатлык берлә базарга таба юнәлде. Аның күз алдына тәрәзәгә куелган бик зур калуш күренде, ул, калуш берлә сөйләгән кебек булып, аңарга таба көлә башлады. Эченнән генә, тукта, көтеп тор, хәзер киләм, менә бу кабәхәтнең генә кирәген бирим, дип, үзенең калушына таба карады. Эченнән үзенең җиңүен, үзенең шул каһәр суккан тишек калушны җиңүен хис итеп тагы алга таба китте. Ул тагы үзенең кесәсенә кулын тиерде, тагы аның акчалары шылтырдап китте. Бу тавыш аның кәефен тагы ачты. Ул тагы, бик һаваланып кына: үз акчам, бер ай өч бала укыткан өчен алган акчам, дип, үзен-үзе эшлеклелеге өчен мактый башлады. Һәркөнне шул ертык калушны киеп укытырга барулары, һәркөнне шул калушны салгач аягыны сөртә-сөртә эштән чыгып арып бетүләре аның күз алдына килде. Ул тагы: менә

хәзер алай булмый инде, аягымда һәйбәт, йылы, йомшак, чиста калуш була, дип уйлады. Ул үзен яңа, йылы калушны кигән кебек хис итте, һәм дә шул фикерен фигыльяткә чыгарыр өчен магазинга борылып керде. Ул, озак сатулашмаенча, калушны алып аягына киде. Калуш аның аягын аз гына кысып матурлатып җибәрде. Ул кулына кәгазьгә төргән иске калушларын күтәреп, акыртын гына ишектән чыкты. Аның аягына бердән йылы булып китте, баягы су чылтыраулары бердән югалды. Аның аягы үзен оҗмахта кебек хис итте. Шул шатлык, шул кәеф аны бөтенләй биләде. Ул бөтенләй шуның ләззәтенә чумды, аңарга хәзер бөтен дөньяның сәгадәте коры, хәзер бөтен дөньяның сәгадәте йылы калуш киюдә, бөтен дөньяның бәхетсезлеге былчырак, тишек калушлы булуда кебек булды. Аның аягының шатлыгы бөтен тәненә тәэсир итте. Аның башы урынына хәзер аягы баш булды, аңарга аның башы түгел, аягы уйлый кебек, аягы бөтен эшне йөртә кебек булды. Ул урам үтә чыкканда үзенең җиңүен тагы ныграк хис итте. Шундагы былчыракларның, суларның моның аягына тия алмауларын, моның йылы аягын туңдыра алмавын күреп, ул тагы һаваланды, эченнән генә: «Шулаймыни, ә, булдыра алмыйсызмы? Шулаймыни? Безнең урамда да бәйрәм булдымыни? Минем 225 тиенлек калушымның астында изелеп каласызмыни?»—дип, аларга хитаб итте. Шул уйларны уйлаган вакытта ул үзенең әллә нәрсәдән риза түгеллеген хис иткән кебек, үзенең әллә нәрсәсе тулмаган кебек булды. Ул шуның хакында озак та уйлап тормады, кулындагы төргән калушның үтә чыккан юеше кәефенең китүенә сәбәп икәнлеген белеп, шуңардан актык мәртәбә үчен алыр өчен калушны Болакка күтәреп бәрде. Аның күңелене тагы шатлык биләде. Үзенең шул уе берлә, калган акча берлә тамакны туйдырыр өчен, бер харчевняга таба борылды. Печән базарының былчырагы, шул былчыракның моның калушына тәгъзыйм кылып, башын иеп калуы аның тагы сәгадәтен зурайтты. Ул, бик зур эш эшләгән кеше кебек, бер зур шәһәрне алган командир кебек, һаваланып кына харчевняга керде. Баскычны менде, ишек янындагы: «Кәфешеңезне салыңыз!» — дигән сүзне күреп, аның «кәфеш» дигән сүзенең көлкелегеннән көләргә онытып, бу әмер, бу хитаб үзенә икәнен, үзенең калушына икәнлеген

уйлап, акыртын, гына калушын салып, башка калушлар янына куйды. Аның калушы аңарга башка калушлардан йылырак, таррак, матурրак кебек күренде. Ул бераз карап торып ләззәтләнгән соңында, залга кереп ашарга сорады. Калуш ләззәте берлә ашны бик тәмләп ашап бетереп, тагы шул йылы, чиста, таза калушны киеп, былчыраклар арасыннан аягын былчыратмаенча өенә кайтыр өчен баскыч янына чыкты. Ул үзенең калушын, куйган урынында күрмәгәч, башка калушлар арасыннан эзләргә тотынды. Аңда да булмады. Ул хезмәтчегә әйтте, ул да эзләде, ул да таба алмады. Калуш югалганны ишетеп, залдагы кешеләр берәм-берәм чыгып калушларын кия башладылар. Калушлыкта бер калуш та калмады. Насыйр бөтен өметен югалтып, итекчән генә кайтырга мәҗбүр булды. Ул Печән базарындагы былчыраклар арасыннан, коры җирен эзләп баса-баса, өенә кайтып китте. Бер почмакта ул, коры җир дип, суга басты, аның бөтен итеге су белә тулды. Аның аягы юешләнде. Аягы үзен-үзе җәһәннәмдә кебек күрде. Ул чыдый алмады: «Әй, калуш, калуш!» — дип кычкырды.

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Манзара* — күренеш.

*Фигълияткә чыгару* —бәхет.

*Хитаб* — мөрәҗәгать.

*Тәгъзыйм* — олылау.

**Калуш** — Хикәя Г.Исхакыйның «Җыентык» (1909) исемле китабында басылган.

Әсәр рус язучысы Н.В.Гогольнең «Шинель»ен хәтерләтә. Әмма хикәядәге сюжет (башмак югалту сюжеты) татар фольклорында да очрый.

*Печән базары* — XVIII гасырның икенче яртысында барлыкка килә һәм 1930 елларга кадәр яши. Казанның хәзерге Киров, Париж Коммунасы һәм

Татарстан урамнарының шактый өлешен биләп, татар байларының эреле-ваклы кибетләре, складлары, харчевнялары белән беррәттән, газета-журнал редакцияләре, «Болгар», «Амур», «Сарай» кебек Г.Тукай, Ф.Әмирхан һ.б. күренекле кешеләр яшәгән кунакханәләр дә урнашкан булган. Татарлар өчен яңалыклар белән уртаклашу, хәбәрләшү үзәге дә булып исәпләнгән бу атаклы базар һәм аның халкы — сатучылары, алучылары, гайбәтчеләре, алдакчылары Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Г.Исхакыйларның әсәрләрендә тәнкыйть һәм сатира объекты булып хезмәт итәләр.

Җамал Вәлиди: «Печән базары» дигәч тә, гади бер печән сата торган урын дип уйларга ярамый. Анда татарның әдәби, икътисади хәяты тәмәркәз итә. Ул татар тормышының иң жанлы бер сәхнәсе. Анда безнең көленерлек, хурланырлык йиремез никадәр күп булса, мактанырлык, куанырлык йиремез дә шундадыр. Шуның өчен инде «Печән базары» дигән сүзне һәрвакыт бер истихкар вә истиһза мәкамендә кулланудан туктарга вакыт!» *(Бер ел узгач,— Вакыт. 1914, 6 февраль.)*

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б. 26-29.